Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районының Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Керәшен Сәрдәсе торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
**КАРАР**

22 октябрь, 2022 ел № 1

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлегенең Керәшен Сәрдәсе торак пунктында 2022 елның 22 октябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 264 (ике йөз алтмыш дүрт).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 145 (йөз кырык биш).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 145 (йөз кырык биш).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез, 2023 елда Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге, Керәшен Сәрдәсе торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү;

**кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Керәшен Сәрдәсе авыл җирлегенен мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге башлыгы Н.В. Морозов